ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Аерым муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 513-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы тарафыннан кертелгән «Аерым муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 513-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2285-VI ДС

Проект Татарстан
Республикасы
Буа муниципаль районы
Советы тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләренең чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1статья**

Әлеге Законга кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы составына керүче «Буа шәһәре», «Татар Буасы авыл җирлеге», «Карлы авыл җирлеге», «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» һәм «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртергә

**2 статья**


«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 1, № 12 (V өлеш); 2010, № 7 (I өлеш); 2014, № 12 (IX өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Буа муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

## «Буа муниципаль районы»
## муниципаль берәмлеге составына керүче
## муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
11 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- җирлекнең административ үзәге
- муниципаль районның административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 6 (7) – 33 (36) | - Апас муниципаль районы |
| 33 (36) – 75 (4) | - Тәтеш муниципаль районы |
| 75 (4) – 79 (4в) | - Ульяновск өлкәсе |
| 79 (4в) – 78 (4г) | - Чүпрәле муниципаль районы |
| 78 (4г) – 70 (5) | - Ульяновск өлкәсе |
| 70 (5) – 67 (6) | - Чүпрәле муниципаль районы |
| 67 (6) – 6 (7) | - Чуаш Республикасы |
| 16 – 16 | - Чуаш Республикасы |
| 63 – 63 | - Чуаш Республикасы |
| 71 (5а) – 82 (5б) | - Чүпрәле муниципаль районы |
| 82 (5б) – 71 (5а) | - Ульяновск өлкәсе |

«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемада № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | «Буа шәһәре» |
| 2 | Адав-Толымбай авыл җирлеге |
| 3 | Аксу авыл җирлеге |
| 4 | Әлши авыл җирлеге |
| 5 | Алших авыл җирлеге |
| 6 | Бик-Үти авыл җирлеге |
| 7 | Зур Фролово авыл җирлеге |
| 8 | Боерган авыл җирлеге |
| 9 | Югары Лашчы авыл җирлеге |
| 10 | Исәк авыл җирлеге |
| 11 | Кайбыч авыл җирлеге |
| 12 | Кыят авыл җирлеге |
| 13 | Күшке авыл җирлеге |
| 14 | Шәмәк авыл җирлеге |
| 15 | Татар Буасы авыл җирлеге |
| 16 | Карлы авыл җирлеге |
| 17 | Мөкерле авыл җирлеге |
| 18 | Түбән Наратбаш авыл җирлеге |
| 19 | Яңа Тинчәле авыл җирлеге |
| 20 | Яңа Чәчкап авыл җирлеге |
| 21 | Норлат авыл җирлеге |
| 22 | Ырынгы авыл җирлеге |
| 23 | Кырык Садак авыл җирлеге |
| 24 | Иске Суыксу авыл җирлеге |
| 25 | Иске Тинчәле авыл җирлеге |
| 26 | Тимбай авыл җирлеге |
| 27 | Күл-Черкене авыл җирлеге |
| 28 | Килдураз авыл җирлеге |
| 29 | Чуаш Киштәге авыл җирлеге |
| 30 | Янтуган авыл җирлеге |
| 31 | Яшевка авыл җирлеге |

»;

2) 2 нче кушымтада:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Буа муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Раково авылыннан 450 м көньякта Чынлы елгасы акваториясендә урнашкан 75(4) нче тоташу ноктасыннан алып, Татарстан Республикасы административ чиге буйлап, Буа муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районының басу аша кишәрлеге һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Новоселки авылыннан 850 м көньяк-көнчыгышка Иске Чынлы елгасы акваториясендә урнашкан 79(4в) нчы тоташу ноктасына, шулай ук Буа муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районының басу аша кишәрлеге һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Новоселки авылыннан 700 м көньяк-көнчыгышта Иске Чынлы елгасы агымында урнашкан 78(4г) нче ноктасыннан алып, Буа, Чүпрәле муниципаль районнары һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Таковары авылыннан 2,7 км төньякта урнашкан 70(5)нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

б) сигезенче абзацта «Буа муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районының басу аша кишәрлеге һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Новоселки авылыннан 700 м көньяк-көнчыгышта Иске Чынлы елгасы агымында урнашкан» һәм «,Буа муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районының басу аша кишәрлеге һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Новоселки авылыннан 850 м көньяк-көнчыгышта Иске Чынлы елгасы агымында урнашкан» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) унынчы абзацта «Татарстан Республикасының административ чиге буйлап 71(5а) нче тоташу ноктасыннан алып 82 (5б) нче тоташу ноктасына» сүзләрен «Татарстан Республикасының административ чиге буйлап 82(5б) нче тоташу ноктасыннан алып 71(5а) нче тоташу ноктасына» сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

««Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Чуашстан Республикасының басу аша кишәрлекләре белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Югары Лашчы, Норлат авыл җирлекләре һәм Чуашстан Республикасының басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында Татар Аксуы авылыннан 1,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып 16 нчы тоташу ноктасына кадәр, шулай ук Кырык-Садак, Янтуган авыл җирлекләре һәм Чуашстан Республикасының басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында Янтуган авылыннан 1,7 км көньяк-көнбатышта Чатказ елгасында урнашкан 63 нче тоташу ноктасыннан алып 63 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

3) 3 нче кушымтада:

а) «2,6 км көньяк-көнбатышта Каилка елгасында урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр» сүзләрен «,100 м Каилка елгасы агымы буенча өскә таба .. 2,0 км көньяк-көнбатышта Каилка елгасында урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Түбән Наратбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, 250 м агач-куак массивы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м профильле автомобиль юлы буйлап бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 450 м сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары чистарту корылмалары чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м, сынык сызык ясап көнчыгышка таба 150 м, сынык сызык ясап көньяк-көнчыгышка таба 100 м, сынык сызык ясап көньяк-көнбатышка таба 250 м бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары җитештерү объекты чиге буенча төньяк-көнбатышка 50 м , сынык сызык ясап көнчыгышка 150 м бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба 150 м сәнәгать объекты буенча, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 50 м Буа – Килдураз автомобиль юлына кадәр бара, аннары әлеге автомобиль юлы буйлап 500 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, төньяк-көнбатышка 150 м, төньяк-көнчыгышка 550 м, төньяк-көнбатышка 100 м Каилка елгасына кадәр уза, аннары Каилка елгасы агымы буенча түбәнгә таба 700 м уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м Буа буйлап, Казан - Ульяновск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, ике тапкыр Карла елгасын һәм агач-куак массивын кисеп үтеп 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары Карлы елгасын һәм агач-куаклык массивын кисеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 550 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 250 м агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап, 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньякка таба, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак үсемлекләренең көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 350 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м агач-куаклык үсемлекләре буенча Карлы елгасына кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча 1,7 км өскә таба бара, аннан соң төньякка таба 25 м агач-куак массивы буенча уза, аннары көнбатышка таба 50 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка 100 м, көнбатышка 200 м, көньяк-көнбатышка 400 м, көньяк-көнчыгышка 200 м уза, аннары көньякка таба 1 км агач-куаклык массивының

көнбатыш чиге буенча сынык сызык ясап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньякка таба 200 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньякка таба 100 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Карлы елгасына кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча өскә таба 20 м «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге, Түбән Наратбаш һәм Карлы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Адав-Толымбай авылыннан 2,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.»;

в) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Карлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 25 м канау буенча, 100 м агач-куак массивының көньяк чиге буенча уза, аннары көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м сынык сызык ясап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 2,0 км агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Карлы елгасына кадәр уза, аннан соң әлеге елганың сул яры буйлап 100 м бара, аннары Буа - Адав-Толымбай - Ивашевка автомобиль юлына һәм Казан - Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, әлеге елга агымы буенча 2,0 км өскә таба уза, 2,9 км Карлы елгасына кадәр бара, аның агымы буенча 100 м өскә таба «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге, Карлы һәм Татар Буасы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Буасы авылыннан 400 м көнчыгышта Карлы елгасында урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

г) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Татар Буасы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 25 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 400 м төньяк-көнбатышка таба Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап уза, әлеге тимер юлның бүлеп бирелгән полосасын кисеп үтеп, 150 м үтә, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка 50 м, төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 200 м бара, 150 м профильле автомобиль юлы буйлап уза, аннары сынык сызык ясап, 100 м төньяк-көнбатышка таба сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көнбатышка таба 100 м сәнәгать объектының көньяк чиге буйлап уза, аннары көньякка таба 50 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 100 м көньякка таба, 100 м көнбатышка таба, 50 м көньякка таба, 50 м көнбатышка таба, 1,0 км төньяк-көнбатышка таба, 350 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м карьерның көнчыгыш, төньяк, көнбатыш чикләре буйлап бара, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге, Татар Буасы һәм Ырынгы авыл

җирлекләре чикләре тоташкан урында Чурак авылыннан 1,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.»;

д) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Ырынгы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып урман полосасын кисеп үтеп 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 25 м Буа-Яльчик автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк - көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 25 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, уза, аннары урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м төньяк-көнчыгышка таба, көньяк-көнчыгышка таба 200 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км, көньяк-көнчыгышка таба 800 м уза, урман полосасын кисеп үтеп, 300 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары урман полосасы буйлап 100 м көнчыгышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 950 м төньяк-көнбатышка, 500 м көньяк-көнчыгышка таба үтә, аннары гомуми юнәлештә агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары көньякка таба 3,0 км Горький тимер юлының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, Горький тимер юлының бүлеп бирелгән полосасын кисеп үтеп, 200 м көнчыгышка таба, сынык сызык ясап бара, аннары төньякка таба 3,3 км Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»

4) 5 нче кушымтаның дүртенче абзацында «Аксу авыл җирлеге, Апас муниципаль районы һәм Чуваш Республикасы чикләре» сүзләрен «Буа, Апас муниципаль районнары» сүзләренә алмаштырырга;

5) 6 нчы кушымтада:

а) бишенче абзацта «Әлши авыл җирлеге, Чүпрәле муниципаль районы» сүзләрен «Буа муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы басу аша кишәрлеге» сүзләренә алмаштырырга;

б) алтынчы абзацта «Чүпрәле муниципаль районы» сүзләрен «Чүпрәле муниципаль районы басу аша кишәрлекләре» сүзләренә, «Чүпрәле муниципаль районы» сүзләрен «Чүпрәле муниципаль районы басу аша кишәрлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

6) 13нче кушымтада:

а) сигезенче абзацта «Каилка елгасында Бикмураз авылыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр» сүзләрен «,100 м Каилка елгасы агымы буенча өскә таба Каилка елгасында Бикмураз авылыннан 2,0 км ераклыкта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза» сүзләренә алмаштырырга;

б) тугызынчы абзацта слова «3,3 км буага кадәр» сүзләрен «3,1 км буага кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

7) 17 нче кушымтада:

а) бишенче абзацта «1,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан» сүзләрен «1,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан» сүзләренә алмаштырырга;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татар Буасы авыл җирлеге чиге «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 25 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 400 м төньяк-көнбатышка таба Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап уза, әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка 50 м, төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 200 м бара, 150 м профильле автомобиль юлы буйлап уза, аннары сынык сызык ясап, 100 м төньяк-көнбатышка таба сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көнбатышка таба 100 м сәнәгать объектының көньяк чиге буйлап уза, аннары көньякка таба 50 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 100 м уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньякка 100 м, көнбатышка 100 м, көньякка 50 м, көнбатышка 50 м, төньяк-көнбатышка 1,0 км, көньяк-көнбатышка 350 м бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м карьерның көнчыгыш, төньяк, көнбатыш чикләре буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.»;

8) 18 нче кушымтаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Карлы авыл җирлеге чиге «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Карлы авыл җирлеге, «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Түбән Наратбаш авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Адав-Толымбай авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 25 м канау буенча, 100 м агач-куак массивының көньяк чиге буенча бара, аннары көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м сынык сызык ясап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 2.0 км агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Карлы елгасына кадәр уза, аннары әлеге елганың сул ярыннан 100 м бара, аннары әлеге елга агымы буенча 2,0 км өскә таба уза, Буа - Адав-Толымбай - Ивашевка автомобиль юлына һәм Казан - Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Карлы елгасының сул ярыннан 2,9 км бара, аның агымы буенча 100 м өскә таба 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

9) 20 нче кушымтада:

а) җиденче абзацта «2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан» сүзләрен «2,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан» сүзләренә алмаштырырга;

б) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Наратбаш авыл җирлеге чиге «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,3 км сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, агач-куак үсемлекләренең массивы буенча 250 м, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м профильле автомобиль юлы буйлап бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 450 м сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары чистарту корылмалары чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м, сынык сызык ясап көнчыгышка таба 150 м, сынык сызык ясап көньяк-көнчыгышка таба 100 м, сынык сызык ясап көньяк-көнбатышка таба 250 м бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары җитештерү объекты чиге буенча төньяк-көнбатышка 50 м , сынык сызык ясап көнчыгышка 150 м бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба 150 м сәнәгать объекты буенча, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 50 м Буа - Черки-Килдуразы автомобиль юлына кадәр бара, аннары әлеге автомобиль юлы буйлап 500 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м төньяк-көнчыгышка таба бара, көньяк-көнбатышка таба 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 300 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 550 м, төньяк-көнбатышка таба 100 м Каилка елгасына кадәр бара, аннары Каилка елгасы агымы буенча түбәнгә таба 700 м уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м буа буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казан-Ульяновск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, ике тапкыр Карлы елгасын һәм агач-куак җирләре массивын кисеп үтеп бара, аннары Карлы елгасын һәм агач-куак массивын кисеп үтеп авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м көньяк-көнбатышка таба бара, алга таба агач-куаклык җирләре массивының көнчыгыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннан соң көньякка, сынык сызык белән 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куаклык җирләре массивының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м ара бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары, агач-куаклык массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м агач-куаклык үсемлекләре буенча Карлы елгасына кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча 1,7 км өскә таба бара, аннан соң төньякка таба 25 м агач-куак массивы буенча уза, аннары көнбатышка таба 50 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка 100 м , көнбатышка 200 м, көньяк-көнбатышка 400 м, көньяк-көнчыгышка 200 м уза, аннары көньякка таба 1 км агач-куаклык

массивының көнбатыш чиге буенча сынык сызык ясап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньякка таба 200 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньякка таба 100 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Карлы елгасына кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча 20 м өскә таба 40 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.»;

10) 24 нче кушымтада:

а) бишенче абзацта «2,6 км көньяк-көнбатышта Каилка елгасында» сүзләрен «2,0 км көньяк-көнбатышта Каилка елгасында» сүзләре белән, «буага кадәр 3,3 км» сүзләрен «буага кадәр 3,1 км» сүзләре белән алмаштырырга;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ырынгы авыл җирлеге чиге «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Ырынгы авыл җирлеге, «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Татар Буасы авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Чурак авылыннан 1,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып, урман полосасын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 25 м Буа-Яльчики автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк - көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 25 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, уза, аннары урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м төньяк-көнчыгышка таба уза, көньяк-көнчыгышка таба 200 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км, урман поласосын кисеп көньяк-көнчыгышка таба 800 м, аннары урман полосасы буйлап 100 м көнчыгышка таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 950 м төньяк-көнбатышка, 500 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап гомуми юнәлештә 100 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары көньякка таба 3,0 км Горький тимер юлының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, Горький тимер юлының бүлеп бирелгән полосасын кисеп үтеп, 200 м көнчыгышка таба, сынык сызык ясап бара, аннары төньякка таба 3,3 км Горький тимер юлының көнчыгыш чиге буйлап 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

11) 27 нче кушымтаның унынчы абзацында «Иске Тинчәле авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында» сүзләрен «Буа муниципаль районының басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында» сүзләренә алмаштырырга;

12) 31нче кушымтада:

а) бишенче абзацта «Чүпрәле муниципаль районы» сүзләрен «Чүпрәле муниципаль районы басу аша кишәрлеге» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 нчы абзацта « Чуаш Киштәге авыл җирлеге, Чүпрәле муниципаль районы чикләре тоташкан урында» сүзләрен «Буа районы, Чүпрәле муниципаль районы чикләре тоташкан урында», сүзләренә «Чуаш Киштәге авыл җирлеге, Чүпрәле муниципаль районы чикләре тоташкан урында» сүзләрен «Буа муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районының басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында» сүзләренә алмаштырырга;

13) 32 нче кушымтаның өченче абзацында «Янтуган авыл җирлеге, Чүпрәле муниципаль районы» сүзләрен «Буа, Чүпрәле муниципаль районнары» сүзләренә үзгәртергә.


**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Муниципаль берәмлекләр чикләренең
үзгәрешләре исәпкә алынган карта-схемасы

"Аерым муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Буа муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законына кушымта




**Шартлы билгеләр**

- Татарстан Республикасы чиге
- Буа муниципаль районы чиге
- Муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б Түбән Наратбаш авыл жирлеге һәм " Буа шәһәре" муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- В-Г Ырынгы авыл жирлеге һәм " Буа шәһәре" муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Г-Д Татар Буасы авыл жирлеге һәм " Буа шәһәре" муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Д-А Карлы авыл җирлеге һәм " Буа шәһәре" муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының " Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге
- Буа муниципаль районының " Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясе
- Буа муниципаль районының " Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Ырынгы авыл җирлеге территориясе
- Буа муниципаль районының " Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге территориясе
- Буа муниципаль районының " Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Карлы авыл җирлеге территориясе

**«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең Түбән Наратбаш, Карлы, Татар Буасы һәм Ырынгы авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү каралган.

Үзгәрешләр Татар Буасы, Карлы, Түбән Наратбаш һәм Ырынгы авыл җирлекләре чикләренә кергән җир кишәрлекләрен Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертүне, шулай ук «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешен Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясе составына кертүне күздә тота.

Өстәмә рәвештә, закон проекты белән 27 нче тоташу ноктасының урыны үзгәрү сәбәпле «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Ырынгы авыл җирлеге белән чиктәш Кайбыч авыл җирлеге чикләренең картографик (текст) тасвирламасы төгәлләштерелә. Шул ук вакытта Кайбыч авыл җирлеге чикләре үзгәрми.

Чикләрне үзгәртү кирәклеге социаль программаларны үтәү өчен дә, Татарстан Республикасының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә шәхси торак төзелеше өчен дә торак төзелеше планын арттыру максатыннан барлыкка килде.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү йөзеннән (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) «Буа шәһәре», «Татар Буасы авыл җирлеге», «Карлы авыл җирлеге», «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» һәм «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләрендә гавами тыңлаулар уздырылды. Фикер алышу нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекләрдә яшәүчеләр чикләрне үзгәртү турындагы инициативаны хуплadылар. Тиешле карарлар күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан кабул ителде. Димәк, законнарда каралган процедуралар үтәлгән.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы чикләренең урнашу урынын рәсми билгеләүгә бәйле рәвештә, Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләре өлешләренең график һәм картографик (текст) тасвирламасы закон проекты белән Чуваш Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш Татарстан Республикасы чигенә туры китерелә. Күрсәтелгән төгәллекләр техник характерда һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законында муниципаль берәмлекләр чикләре тасвирламасына туры килә.

Закон проекты 2, 3, 5, 6, 13, 17, 18, 20, 24, 27, 31, 32 кушымталарга үзгәрешләр кертергә, шулай ук «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә тәкъдим итә.

Закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарга китермәячәк.

**«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул ителергә тиешле норматив хокукый актлар исемлеге**

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү һәм кабул итүне таләп итми.

**«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС- ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанс чаралары бүлеп бирүне таләп итми.